ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 06 2020 г. № 417

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган «Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, шулай ук муниципаль функцияләрне үтәүне оптимальләштерү һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру максатларында, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган «Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 25 нче июнь
417 нче номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган
«Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. Административ регламентның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары,
аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада
административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт алу өчен, мөрәҗәгать итүче-бюджет оешмасы хезмәткәре исемлек төзелә һәм Яшьләр эшләре идарәсенә тапшырыла торган бюджет учреждениесенең профсоюз оешмасына шәхсән мөрәҗәгать итә. Үз чиратында, Яшьләр эшләре идарәсе, юллама алырга теләүчеләр реестрын формалаштырганнан соң, сәламәтләндерү-ял итү учреждениесенә, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәгенә (алга таба –Үзәк) тапшыра (административ регламентка 1 нче кушымта).

Ата-аналары муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шул исәптән федераль буйсынудагы дәүләт оешмалары хезмәткәрләре булган балалар өчен юлламаларны бүлү квотасы:

| т/с | Оешма исеме | 21 көнлек 2 сменага квота | | 18 көнлек сменага квота | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Кама | Заря | Кама | Заря |
| 1. | РФ Дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре профсоюзы | 45 | 30 | 47 | 20 |
| 2. | Мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы | 15 | 20 | 10 | 15 |
| 3. | Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзы | 20 | 25 | 13 | 15 |
| 4. | Мәгариф хезмәткәрләре профсоюзы | 30 | 25 | 15 | 15 |
| 5. | Мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәрләре профсо-юзы | 30 | 30 | 17 | 15 |
| 6. | Көч һәм хокук структуралары (ЭЭМ, ГТХМ, Ведомстводан тыш сак бүлеге, Эчке эшләр идарәсе, Җәзаларны үтәү федераль хезмәте идарәсе, Федераль куркынычсызлык хезмәте, суд һ. б.), салым, Роспотребнадзор, Пенсия фонды, Социаль яклау идарәсе һ. б.) | 28 | 20 | 8 | 15 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| БАРЛЫГЫ: | 168 | 150 | 95 | 95 |

Лагерь сменасы башланырга 7 көн кала 1-6 пунктта күрсәтелгән юлламаларның квотасы ихтыяҗсыз кала икән, алар башка категорияләр арасында, ихтыяҗ буенча, яңадан бүленә.

Ихтыяҗны Яшьләр эшләре идарәсе резервка бирелгән гаризаларны анализлау юлы белән терки.

3.1.1. Башка учреждениеләр гражданнары юлламалар алу өчен түбәндәге адрес буенча КФҮ гә шәхсән мөрәҗәгать итәләр: Мәктәп бульвары, 2А.

3.2. Путевка алу өчен ата-ана яки башка законлы вәкил смена башланганчы 30 календарь көннән дә соңга калмыйча КФҮ гә әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

3.2.1. 3.2 п. нигезендә документлар тапшыру мөмкинлеге булмау сәбәбенә әверелә торган Татарстан Республикасында һәм Түбән Кама муниципаль районында котылгысыз көч, табигый бәла-казалар, имин булмаган санитар-эпидемиологик хәл булган очракта, юлламаларны бүлү, башкарма комитет тарафыннан махсус төзелгән комиссия фикерен исәпкә алып, Яшьләр эшләре идарәсе тарафыннан билгеләнә.

3.3. балалар сәламәтләндерү лагерена, Үзәккә юллама алу өчен гариза һәм кушып бирелә торган документлар гаризаларны теркәү өчен махсус журналда кабул ителгән көнне балалар сәламәтләндерү лагеры, Үзәк белгече (юлламалар сату буенча белгеч) тарафыннан теркәлә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.4. Гаризалар гариза бирелгән көннән өч эш көне эчендә балалар сәламәтләндерү лагере, Үзәк тарафыннан карала.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, муниципаль хезмәт алучылар, аның законлы вәкилләре смена башланганчы ундүрт көн кала, квитанция буенча түлиләр һәм түләү турындагы документ булганда, КФҮ дә юллама алалар. Шулай ук юлламаны алганда, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына китү урыны һәм вакыты турында тулы мәгълүмат бирелә.

Юлламаны түләү акчасыз башкарыла. Юлламаларга түләү өчен банк реквизитлары муниципаль хезмәт күрсәтү урыны буенча – КФҮ тарафыннан күрсәтелә.

Процедураның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт алучы алган юллама.

3.5. Балалар сәламәтләндерү лагере, Үзәк администрациясе балаларны лагерьга бары тик балалар сәламәтләндерү лагере (Үзәк) директоры имзалаган юллама булганда гына кабул итә.

3.6. Юлламаларны бирү, әлеге регламентның 3.3 пункты нигезендә, һәр учреждениенең тиешле журналында гариза һәм кушып бирелә торган документларны теркәү датасына карап, чират нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Түбән Кама муниципаль районының балалар һәм яшүсмерләр өчен 18 көнлек профильле смена вакытында юлламаларны бүлү квотасы. Түбәндәге таблицаның 9 пунктыннан тыш, һәр лагерьда елга ике сменадан да артык булмаган вакыт эчендә кулланыла:

| № | Ял итүче балалар категориясе | «Кама» үзәге | «Заря» балалар сәламәтләндерү лагере |
|---|---|---|---|
| 1. | Профилактик исәптә торучы балалар (социаль куркыныч хәлдәге, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядәге гаиләләр һ. б.) | 5 | 5 |
| 2. | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага яки тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар. | 5 | 5 |
| 3. | Үз-үзләренә хезмәт күрсәтә ала торган инвалид балалар | 5 | 1 |
| 4. | Ата-анасы икесе дә инвалид яки бердәнбер ата-анасы инвалид булган балалар | 5 | 5 |
| 5. | Күпбалалы гаилә балалары (5 һәм аннан да күбрәк бала) | 10 | 5 |
| 6. | Муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шул исәптән федераль буйсынудагы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары | 97 | 95 |
| 7. | Башка оешмаларның (муниципаль һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларның) хезмәткәрләре балалары | 25 | 34 |
| 8. | Ата-аналары COVID-19 булган пациентларны дәвалаучы медицина учреждениеләре хезмәткәрләре булган балаларга | 13 | - |
| 9. | Ата-аналары «Ана даны» медале алган балалар (бары тик 1 нче сменада гына кулланыла) | 3 | - |
| Барлыгы | | 168 | 150 |

Әгәр смена башланганчы 7 көн кала 1-4 п.п. да күрсәтелгән юлламалар квоталарына ихтыяҗ булмый икән, алар 1-4 п.п. да күрсәтелгән категорияләр арасында, ихтыяҗ буенча, яңадан бүленә.

Әгәр смена башланганчы 7 көн кала 5 п. күрсәтелгән юллама квотасына ихтыяҗ булмый икән, алар 6-7 п.п. да күрсәтелгән категорияләр арасында, ихтыяҗ буенча, яңадан бүленә.

Ихтыяҗны Яшьләр эшләре идарәсе резервка бирелгән гаризаларны анализлау юлы белән терки.

3.7.1 21 көнлек сменалар үткәрү чорында Түбән Кама муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр өчен юлламаларны бүлү квотасы:

| № | Ял итүче балалар категориясе | «Кама» үзәге |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шул исәптән федераль буйсынудагы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары | 148 |
| | Ата-аналары COVID-19 булган пациентларны дәвалаучы медицина учреждениеләре хезмәткәрләре булган балаларга | 20 |
| Барлыгы | | 168 |

3.8. Балалар сәламәтләндерү лагерена юллама агымдагы елның җәйге сезонында бер тапкыр бирелә:

- «Кама» балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәгенә - 7 яшьтән 16 яшькә кадәрге балалар өчен;
- «Заря» лагерена – 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалар өчен.

Икенче тапкыр юллама алуга элек мөрәҗәгать иткән гражданнарның юллама алуга ихтыяҗы булмаган яки балалар сәламәтләндерү лагеры сменасы тулы

комплектланмаганда гына дәгъва итә ала. Шул ук вакытта күрсәтелгән юллама затка, гариза бирү датасына карап, чират буенча бирелә.

3.9. Юлламалар, ялны оештыру формасына карап, аның факттагы бәясен өлешчә түләү шартларында бирелә:

| № | Ял итүче балалар категориясе | Ата-аналар түләве | |
|---|---|---|---|
| | | «Кама» үзәге | «Заря» балалар сәламәтләндерү лагере |
| 1. | Профилактик исәптә торучы балалар (социаль куркыныч хәлдәге, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядәге гаиләләр һ. б.) | 15% | 15% |
| 2. | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага яки тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар. | 15% | 15% |
| 3. | Үз-үзләренә хезмәт күрсәтә ала торган инвалид балалар | 15% | 15% |
| 4. | Ата-анасы икесе дә инвалид яки бердәнбер ата-анасы инвалид булган балалар | 15% | 15% |
| 5. | Күпбалалы гаилә балалары (5 һәм аннан да күбрәк бала) | 15% | 15% |
| 6. | Муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шул исәптән федераль буйсынудагы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары | 35% | 30% |
| 7. | Башка оешмаларның (муниципаль һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларның) хезмәткәрләре балалары | 45% | 40% |
| 8. | Ата-аналары COVID-19 булган пациентларны дәвалаучы медицина учреждениеләре хезмәткәрләре булган балаларга | 15% | 15% |
| 9. | Ата-аналары «Ана даны» медале алган балалар | 15% | 15% |

1-4 п.п. һәм 8-9 пунктларында күрсәтелгән балаларның ата-аналарына хезмәт бушлай күрсәтелә, ата-аналар кертеме җирле бюджеттан компенсацияләнә.

3.10. Балалар сәламәтләндерү лагерена бирелгән юлламаларны исәпкә алу сәламәтләндерү-ял итү учреждениесе, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәге белгече тарафыннан юлламалар бирүне исәпкә алуның махсус журналында башкарыла.

3.11. Әгәр бала сәламәтләндерү-ял учреждениесенә, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәгенә керү көнендә килмәгән булса, гариза бирүче смена башыннан 2 көн дәвамында сәламәтләндерү учреждениесе (Үзәк) директоры исеменә күчерелгән акчаларны кире кайтару турында язмача сорату ясарга хокуклы. Калган очракларда акча кире кайтарылмый. Кире кайтарылган юлламаны әлеге Регламентның 3.7 пунктында күрсәтелгән тәртип буенча кабат сатып алырга мөмкин.

3.12. Сәламәтләндерү-ял учреждениесе, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәге администрациясе баланы

сәламәтләндерү-ял учреждениесеннән, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәгеннән, сәламәтләндерү-ял учреждениесенең, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәгенең эчке тәртип кагыйдәләрен бозган өчен, юлламаның бәясен капламыйча гына чыгарырга хокуклы.

3.13. Гариза бирүчеләрне шәхси кабул итү сәламәтләндерү-ял учреждениесе, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм мәшгульлеген оештыру үзәге директоры, Яшьләр эшләре буенча идарә башлыгы, аларның урынбасарлары, яки бу эшкә вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә.

Алдан язылу һәм гражданнарны исәпкә алу журналда корреспонденция теркәүче белгеч тарафыннан алып барыла. Шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.

3.14. Авыр тормыш хәлендә калган балаларны балалар өчен шәһәр читендәге ял һәм сәламәтләндерү лагерьларына ташламалы юлламалар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары белән расланган балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турындагы нигезләмәнең 3.3 һәм 11 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Административ регламентка 1 нче кушымтаны әлеге үзгәрешләргә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

3. Административ регламентка 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Административ регламентка 3 нче кушымтаны әлеге үзгәрешләргә 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

«Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләргә
1 нче кушымта

Административ регламентка
1 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы учреждениеләр турында мәгълүматлар

| т/с | Учреждение исеме | Урнашу урыны | Директор | Телефон |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Заря» балалар сәламәтләндерү лагере» МБУ | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Шәңгәлче авылы | Борисов Сергей Иванович | 43-08-42 |
| 2 | «Кама» үзәге» МБУ | Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Красный Ключ поселогы, Совет урамы, 35 йорт | Юртаева Екатерина Леонидовна | 49-92-73 |

«Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләргә
2 нче кушымта

Административ регламентка
3 нче кушымта

Административ регламентка үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат

| Вазыйфа | Телефон | Кабул итү урыны | Кабул итү көне һәм сәгатьләре |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе әйдәп баручы белгече | (8555) 43-08-42 | Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Актүбә урамы, 6 йорт, 311 кабинет | дүшәмбе-җомга 8.00 - 17.00 |